# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

07 08 2026 ел Яр Чаллы ш. №2702

«Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүдә, шул исәптән янгыннан ирекле саклау эшчәнлегендә гражданнарның катнашу формаларын билгеләү турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 05 октябрендәге 3921 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. «Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүдә, шул исәптән янгыннан ирекле саклау эшчәнлегендә гражданнарның катнашу формаларын билгеләү турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 05 октябрендәге 3921 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Янгын сүндерүдә һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруда катнашкан һәм, әгәр бу вакытта чиктән тыш зарурлык чикләрен арттыруга юл куелмаган булса, янгыннан ирекле саклау буенча акланган куркыныч һәм (яки) чиктән тыш зарурлык шартларында эшләгән шәхси состав Россия Федерациясе законнары нигезендә матди зыян китергән өчен җаваплылыктан азат ителергә мөмкин.».

1.2. 5.4 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 2 абзацны өстәргә: «Янгын сүндерүдә һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкаруда катнашкан һәм, әгәр бу вакытта чиктән тыш зарурлык чикләрен арттыруга юл куелмаса, янгыннан ирекле саклауның акланган куркыныч һәм (яки) чиктән тыш зарурлык шартларында эшләгән шәхси составы коткарылучы кешеләрнең, янгыннан саклау шәхси составының, янгын сүндерүдә катнашучы башкаларның сәламәтлегенә зыян китергән яки аларның үлеме өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыктан азат ителергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районының «Гражданнарны яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе И.И. Якуповка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов